Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Кадыровского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул.Молодежная , д. 1, с.Кадырово,
Заинский район, 423513

Татарстан Республикасы
Зәймуниципаль районы
Кадер авыл җирлеге
Башкарма комитеты

Яшьлэр урамы, 1 нче йорт, Кадер авылы,
Зәй районы, 423513

Телефон, факс 63-3-18. Электронный адрес: Kadir.zai@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 08.04.2025 № 11

**Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлеге
территориясендә йорт
хайваннарын йөртү
урыннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 25.12.2018 елгы 136 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен, күрү сәләте буенча инвалидны озата йөрүче юл күрсәтүче эттән тыш, түбәндәге урыннарны билгеләргә:
- файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;
- халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борынчыкларда һәм бауларда аларның хуҗалары күзәтүе астында:
- Әхмәт авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Т. Ялчыгол урамыннан 60 метр ераклыкта;

- Кадер авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Үзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Туңылҗа авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Үзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Федотово авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Үзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Киселевка авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Үзәк урамнан 60 метр ераклыкта.

Әлеге пунктның тәэсире эт йөртүчеләргә кагылмый.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Руководитель**
**Исполнительного комитета** **Л.Н. Барсукова**